**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_11.09.2024_ __995-п__

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 мартындагы 192-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 мартындагы 192-п номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 31.08.2022 ел, №755-п, 14.03.2023 ел, №263-п һәм 06.06.2023 ел, №695-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибендә:

1.4 пунктның 3 подпунктында «Җир асты байлыклары турындагы законның $36^1$» сүзләрен «Җир асты байлыклары турындагы законның $23^6$» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның 1, 3 пунктчаларында «Җир асты байлыклары турындагы законның $36^1$» сүзләрен «Җир асты байлыклары турындагы законның $23^6$» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге белгече җибәрелгән хокук бозулар һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату ихтималы турында хәбәргә кул куелган көннән алып өч эш көне эчендә аны «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләүнең автоматлаштырылган системасы» (алга таба – «АСЛН» ФДМС) федераль дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыра. Урнаштырылганнан соң (Хәбәр файлы «АСЛН» ФДМСтагы лицензиягә беркетелгәннән соң) икенче эш көнендә әлеге хәбәр Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар һәм геологик оешмалар порталында «АСЛН» ФДМСта «Җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты»нда (алга таба – ЛКН) лицензия паспортында күрсәтелә, бу хакта җир асты байлыкларыннан файдаланучы Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре порталында тиешле белдерү ала. Хәбәр ЛКН урнаштырылганнан соң 30 көн узгач тапшырылган дип санала.»;

3.5 пунктның 2 пунктчасында «аларны үткәрү тәртибен һәм срокларын» сүзләрен «аларны үткәрү тәртибен» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге белгече җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яки чикләү турындагы боерык проектына кул куелган көннән алып өч эш көне эчендә әлеге карарны «АСЛН» ФДМС тиешле язма кертү (карарны лицензия файлына беркетү) һәм «АСЛН» ФДМС лицензияләр реестрында лицензия статусын үзгәртү юлы белән урнаштыра. Үзгәртелгән статус «АСЛН» ФДМС лицензияләр һәм ЛКН реестрында чагылдырыла, бу хакта җир асты байлыкларыннан файдаланучы Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре порталында тиешле белдерү ала. Боерык ЛКН урнаштыру көненнән тапшырылган дип санала.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм чикләү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан түбәндәгеләрне чыгарырга:

Вахитова Елена Камил кызын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгын;

Полюшков Алексей Сергеевичны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгын.

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Заһидуллин Роберт Айвар улын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгын;

Алимов Гадел Равил улын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының геологик күзәтчелек бүлеге башлыгын.

Министр А.В. Шадриков